Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы

КАРАР

17 декабрь 2019 ел № 131

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 18 июнендәге 112 номерлы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында» 2013 елның 25 июнендәге 50 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, «Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында «Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 01.04.2009 елдагы 48-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә»гә «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советының 2019 елның 18 июнендәге 112 номерлы карары белән расланган (Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советының 2019 елның 10 октябрендәге 123 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. нигезләмәнең 21 бүлегендәге 21.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21.13. Әлеге бүлекнең 21.12 пункты нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм булу, кулдагы акчаларны һәм кыйммәтләрне саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалану тыелу турында» 7 май, 2013 ел, № 79-ФЗ Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү фактларын ачыклаганда, Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты - район Башкарма комитеты җитәкчесе депутатның, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты тарафыннан яисә күрсәтелгән затларга карата тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә судка бүтән җаваплылык чараларын куллану турында гариза белән мөрәҗәгать итә».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Нурлат шәһәре Советы рәисе А.С. Әхмәтшин